ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2005, № 7 – 8; 2008, № 5 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 7 пунктында «барлык милек рәвешләрендәге оешмалар» сүзләреннән соң «(алга таба – барлык милек рәвешләрендәге оешмалар)» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ статья өстәргә:
«$8^1$ статья. **Барлык милек рәвешләрендәге оешмаларның махсуслаштырылган оешмалар белән хезмәттәшлеге**

Барлык милек рәвешләрендәге оешмалар үзләре кабул иткән карарлар нигезендә торак шартларын социаль ипотека системасында яхшыртуга мохтаҗ хезмәткәрләренең гаиләләрен исәпкә ала һәм аларның реестрын алып бара, реестрны махсуслаштырылган оешмаларга бирә.»;

3) 9 статьяда:
а) 1 пунктта «торак төзелеше үсешен финанслауда катнашучы» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 11 пунктта «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «, барлык милек рәвешләрендәге оешмалар» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 28 марты
№ 17-ТРЗ